# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Тойгелде авыл җирлеге Ташлыяр торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

23 ноябрь 2023 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Тойгелде авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 14.10.2019 1 нче номерлы карары нигезендә 2023 елның 23 ноябрендәге гражданнар җыены нәтиҗәләреннән түбәндәге мәсьәләләр буенча беркетмә төзелде:

«Сез, 2024 елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге Ташлыяр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000,00 (бер мең) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 500,00 (биш йөз) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, һәм шулай ул хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә» һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

1) **Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге**

- кышкы чорда Ташлыяр авылы эчендәге юлларны карап тоту, Уңыш, Яр буе урамнарны кардан чистарту шартнамәсе буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, җирләү урыннарына кадәр эчке юлларны чистарту;
- Уңыш, Яр буе урамнары буенча вак таш өслек кулланып юлларны ремонтлау, шартнамә буенча эшләр өчен түләү;
- җәй көне авыл эчендәге Уңыш, Яр буе урамнары буенча юлларны карап тоту;

2) **урамнарны яктырту**

- Уңыш, Яр буе урамнары буенча тышкы яктырту челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау;
- светодиодлы лампалар, кронштейннар һәм комплектлау материаллары сатып алу;
- урам яктыртуы өчен;

**3) су белән тәэмин итү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, су ташуны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын ремонтлау**

- Ташлыяр авылында су белән тәэмин итү системаларын, су белән тәэмин итүче су башняларын ремонтлау һәм карап тоту
- Ташлыяр авылында су башнялары территорияләрен төзекләндерү, чистарту, чабу
- Ташлыяр авылында эчә торган суның сыйфаты буенча лаборатория тикшеренүләре үткәрү;

4) **халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның күпләп ял итү өчен башка урыннар) төзекләндерү һәм янәшәсендәге территорияләрне төзекләндерү**

- «Сабантуй» урынын төзекләндерү

- Ташлияр авылында спорт мәйданчыгын урнаштыру
- халыкның күпләп ял итү урыннарындагы үләнне чабу;

**5) традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү**

- каты көнкүреш калдыкларын зиратлардан чыгару
- зиратка керү урынында Бөек Ватан сугышында катнашучыларның исемнәре белән табличкалар урнаштыру
- кыргый үсентеләрне һәм агачларны кисү
- җирләү урыннарының үләннәрен чабу;

**6) янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү**

- янгыннарны бетерү өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу

**7) обелискларны ремонтлау һәм алар янындагы территорияләрне төзекләндерү**

- Бөек Ватан сугышында һәлак булучыларның һәйкәлләрен ремонтлау, территорияне төзекләндерү;

**8) яр буе зоналарын чистарту**

- Кәүҗияк инеше яр буе зоналарын чистарту, чүп-чар чыгару?

«РИЗА» «КАРШЫ» «БИТАРАФ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 248 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 142, бу 57% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 142 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 0 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен, 0 кеше «БИТАРАФ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлегенең Ташлыяр торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге Ташлыяр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000,00 (бер мең) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 500,00 (биш йөз) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, һәм шулай ул хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә.

3. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) **Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге**

- кышкы чорда Ташлыяр авылы эчендәге юлларны карап тоту, Уңыш, Яр буе урамнарны кардан чистарту шартнамәсе буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, җирләү урыннарына кадәр эчке юлларны чистарту;
- Уңыш, Яр буе урамнары буенча вак таш өслек кулланып юлларны ремонтлау, шартнамә буенча эшләр өчен түләү;
- җәй көне авыл эчендәге Уңыш, Яр буе урамнары буенча юлларны карап тоту;

2) **урамнарны яктырту**

- Уңыш, Яр буе урамнары буенча тышкы яктырту челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау;
- светодиодлы лампалар, кронштейннар һәм комплектлау материаллары сатып алу;
- урам яктыртуы өчен;

**3) су белән тәэмин итү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, су ташуны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын ремонтлау**

- Ташлыяр авылында су белән тәэмин итү системаларын, су белән тәэмин итүче су башняларын ремонтлау һәм карап тоту
- Ташлыяр авылында су башнялары территорияләрен төзекләндерү, чистарту, чабу
- Ташлыяр авылында эчә торган суның сыйфаты буенча лаборатория тикшеренүләре үткәрү;

4) **халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның күпләп ял итү өчен башка урыннар) төзекләндерү һәм янәшәсендәге территорияләрне төзекләндерү**

- «Сабантуй» урынын төзекләндерү
- Ташлияр авылында спорт мәйданчыгын урнаштыру
- халыкның күпләп ял итү урыннарындагы үләнне чабу;

**5) традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү**

- каты көнкүреш калдыкларын зиратлардан чыгару
- зиратка керү урынында Бөек Ватан сугышында катнашучыларның исемнәре белән табличкалар урнаштыру
- кыргый үсентеләрне һәм агачларны кисү
- җирләү урыннарының үләннәрен чабу;

**6) янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү**

- янгыннарны бетерү өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу

**7) обелискларны ремонтлау һәм алар янындагы территорияләрне төзекләндерү**

- Бөек Ватан сугышында һәлак булучыларның һәйкәлләрен ремонтлау, территорияне төзекләндерү;

**8) яр буе зоналарын чистарту**

- Кәүҗияк инеше яр буе зоналарын чистарту, чүп-чар чыгару.

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Тойгелде авыл җирлеге башлыгы Минһаҗев Д.М.